**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ҮЗӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

# КАРАР

икенче утырыш

**Үзәк пос.** **№8** **14 октябрь 2025 ел**

**2025 - 2026 елларга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фаразлау планын (Программасын) раслау турында**

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районының Үзәк авыл җирлеге Советы:

1. 2025 – 2026 елларга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фаразлау планын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Үзәк авыл җирлеге башлыгы В.Н. Котников

**2025 – 2026 елларга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фаразлау планы**

**I бүлек. Мөлкәтне хосусыйлаштыру өлкәсендә төп юнәлешләр**

Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең 2025 - 2026 елларга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) (алга таба –хосусыйлаштыру программасы) гамәлгә ашыруның төп максаты- муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү.

2025, 2026 елларда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Теләче муниципаль районы Советының 2011 елның 11 июлендәге 53 номерлы карары белән расланган «Теләче муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмә (03.09.2014 №221, 13.11.2017 №110 үзгәрешләр белән) нигезендә гамәлгә ашырыла.

1. 2025-2026 елларда мөлкәтне хосусыйлаштыру бурычлары.

Чираттагы елда мөлкәтне хосусыйлаштыру бурычлары булып тора:

- муниципаль мөлкәт белән нәтиҗәле идарә итү нигезендә авыл җирлеге бюджеты керемнәрен арттыру;
- икътисадый үсешне тәэмин итү, җир һәм башка күчемсез милек базарын үстерү, предприятиеләрнең рентабельле һәм тотрыклы эшләвенә ирешү максатларында милек структурасын оптимальләштерү;
- муниципаль милек объектларының максималь санын граждан әйләнешенә җәлеп итү;
- хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итү.

2. Район икътисадында, шул исәптән икътисадның конкрет тармакларында (идарә өлкәләрендә) хосусыйлаштыруның структур үзгәрешләргә йогынтысы фаразы.

2025 - 2026 елларда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль мөлкәт объектлары исемлегенә Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге муниципаль милкендәге объектлар кертелгән.

Тулаем алганда, 2025-2026 елларга Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планында (программасында) күрсәтелгән мөлкәт объектларын хосусыйлаштыру Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге икътисадында структур үзгәрешләргә йогынты ясамаячак, шул исәптән икътисадның конкрет тармакларында (идарә өлкәләрендә).

3.2025-2026 елларда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль мөлкәт исемлеге Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Советы карарлары нигезендә күчемсез мөлкәтнең яңа объектлары белән тулыландырылырга мөмкин.

**II бүлек.**
**1.2025 - 2026 елларда хосусыйлаштыру фаразлана торган муниципаль күчемсез мөлкәт исемлеге**

| № т/б | Күчемсез милек объекты исеме | Урнашу урыны (адресы) | Гомуми мәйдан (кв.метр) |
|---|---|---|---|
| 1 | Азык цехының торак булмаган бинасы, кадастр номеры 16:40:110103:393, җир кишәрлеге белән | Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Үзәк авыл җирлеге | 400 |
| 2 | Терлекчелек фермасының торак булмаган бинасы - корпус №1, кадастр номеры 16:40:110103:394, җир кишәрлеге белән | Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Үзәк авыл җирлеге | 1571,6 |
| 3 | Терлекчелек фермасының торак булмаган бинасы - корпус №2, кадастр номеры 16:40:110103:433, җир кишәрлеге белән | Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Үзәк авыл җирлеге | 1532,7 |
| 4 | Ашханә торак булмаган бина, кадастр номеры 16:40:110501:546, җир кишәрлеге белән | Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Үзәк авыл җирлеге, Үзәк пос., Хаҗиев ур., 10 йорт | 552,5 |
| 5 | Ат абзарлары торак булмаган бина, кадастр номеры 16:40:110:431, җир кишәрлеге белән | Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Үзәк авыл җирлеге | 683 |
| 6 | Терлекчелек фермасының торак булмаган бинасы, кадастр номеры 16:40:110103:434, җир кишәрлеге белән | Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Үзәк авыл җирлеге | 1671 |
| 7 | Терлекчелек фермасының торак булмаган бинасы, кадастр номеры 16:40:110103:432, җир кишәрлеге белән | Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Үзәк авыл җирлеге | 806,6 |